| СОВЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **Р Е Ш Е Н И Е** | | **К А Р А Р** |
| **27 декабрь 2024** | Болгар ш. | **№ 44-3** |

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турындагы нигезләмәне раслау хакында «Татарстан Республикасы «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 30 декабрендәге 6-7 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турындагы нигезләмәне «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2005 елның 30 декабрендәге 6-7 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 елның 30 декабрендәге 6-7 номерлы Татарстан Республикасы «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 3.41 пункт өстәргә:

«3.41. Үз функцияләрен тәэмин итү өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын, шулай ук пространстволы мәгълүматларның милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын файдалана.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spassriy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru игълан итәргә.

Спас муниципаль районы Советы башлыгы,
Рәисе Ф.В. Мөхәммәтов